ЭШ БУЛСЫН!

Татарстанда машина двигательләре җыя башладылар

> 2

ГАЛӘМДӘГЕ ТАМАША

«ВТ» хәбәрчесе «Вызов» фильмын төшерүдә катнашкан космонавт белән аралашты

> 3

ТҮЛӘҮСЕЗ ТҮБӘ

Россия Үзәк банкы ипотекага алмаш тәкъдим итә

> 3



РӘХМӘТЛЕ АЛИНӘ

Орчык кадәр кыз авылда яшәүче ике кешенең гомерен саклап калган

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 97 (29064) | Сишәмбе | 11 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЯЛДАН АРЫМА

БАЛА БЕЛӘН ЯЛ ИТКӘНДӘ НӘРСӘНЕ ИСТӘ ТОТАРГА?

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Барыргамы, бармаскамы? Бала белән ялга җыенган ата-аналар үзләренә бу сорауны бирми калмыйдыр. Сер түгел бит: бала белән ял – остәмә җаваплылык та, мәшәкать тә, хезмәт тә. «ВТ» ял имин һәм күңелле узсын өчен нишләргә кирәк икәнен белеште.

Ялның була төрлесе

Журналист Нәзилә Хуҗина-Җәлалиева бу җәйдә баласы белән Анападагы санаторийда ял итә. Биш яшьлек сабыйның беренче сәяхәте икән.

– Ике көн машина белән юлда булдык. Озын юл авыр булмасмы дип борчылган идем, «эх» та итмәде кызыбыз! – дип сөенә әни. – Телефонда утырырга рөхсәт итмәдем, күбрәк юлны карап барды. Буягычлар алган идек, шулар белән мәш килде. Тынгысыз, сикерергә, чабарга яраткан бала өчен гаҗәп күренеш инде бу.

Диңгезгә әле бер генә тапкыр барырга өлгергәннәр. Һава торышы көйсез икән: әле яңгыр, әле җил.

– Бала белән ял итү бик ошый. Бәлки, беренче мәртәбә булгангадыр, – ди Нәзилә. – Бәлки, бернинди көн генә булгангадыр, әле арып өлгермәдек.

Казанда яшәүче Мария Зайцева исә бала белән ял итүдән тәм тапмый.

– 18 яшькәчә балалар белән ял итү – ял түгел инде ул. Сәяхәттә алар артыннан күз-колак булырга, тегендә бармасын, монысын эшләмәсен дип торырга кирәк. Бу хакта уйламыйча тору мөмкин булмагач, ялмыни инде ул? – ди Маша. – Балама өч яшь чагында икәү ял итәргә киттек. Поездда сәяхәт итүне уңайлырак дип таптык. Имеш, поезд тәрәзәсеннән табигатькә карап барачакбыз, китаплар укыячакбыз. Документларымны барлыйм дип, бернічә секунда гына баламның кулын ычкындырган идем – югалттым! Игътибарын перрондагы бер эт җәлеп иткән икән. Шуны сыйпарга дип киткән бу.

Колагыңа киртләп куй!

Июль – август – ял итү сезонының иң кызган чоры. Әнигә дә, бәбигә дә кирәк ул ял. Әмма диңгез буенда кызынып ятуга хыялланудан битәр ялның имен җибәрердәй очракларны булдырмас өчен алдан аяк кинәсе. Нәрсә турында онытмаска соң?

ДОКУМЕНТЛАР. Әгәр бала әти-әнисе белән чит илгә сәяхәткә җыена икән, аңа үзе белән чит ил паспорты алырга кирәк. Туу турында яки опека турында таныклыкны да онытмаска. Анысын чик чыкканда тикшерергә мөмкиннәр. Әгәр баланың фамилиясе ата-анасының фамилиясе белән туры килмәсә, фамилия үзгәртүне раслаучы документ та кирәк.

Баланы әти-әнисе генә түгел, гаиләнең теләсә кайсы әгъзасы да ял итәргә алып китә ала, билгеле. Моның өчен аларга законлы вәкилләрнең берсеннән нотариаль рәвештә расланган ризалык кәгазе кирәк. Килешүдә

«Татар-информ»

баланы алып чыгып була торган илләр, сәяхәт вакыты һәм озата баручылар турында мәгълүмат күрсәтелергә тиеш.

ПРИВИВКАЛАР. Чит илгә чыгам дип кенә сәламәтлек турында да онытырга ярамый. Роспотребнадзор белгечләре алдан ук «сәламәтлек саклау календаре»на кергән прививкаларны ясатканмы-юкмы икәнне ачыкларга киңәш итә. Сүз дифтерия, бума ютәл (коклюш), кызамык, паротит, кызылчадан прививкалар турында бара. Әгәр дә ревакцинация вакыты җитсә, аны сәяхәткә кадәр эшләтсәгез яхшырак.

Тере янсә бу илгә барыр алдыннан туроператордан әлеге илдәге эпидемиологик вазгыять турында белешү зарур. Өстәмә прививкалар ясатырга кирәк булуы һәм шул хакта белешмә сораулары ихтимал.

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК КАГЫЙДӘЛӘРЕ. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының мәгълүматларына карaганда, ялдагы күп кенә бәла-казалар сулыкларга туры килә. Шуңа да су керү кагыйдәләрен истә тотарга киңәш итә белгечләр.

Сан

Россия Туроператорлары ассоциациясе фаразлавынча, бу җәйдә чит илләргә **5** миллионга якын россияле барырга җыена. Бу узган ел белән чагыштырганда **42** процентка күбрәк.

Су керүне иртәнге янсә кичке вакытка калдырырга киңәш итәләр. Бу вакытта әле кояш артык кыздырмый. Су керү өчен иң яхшы һава торышы – җилсез, 25 градус һәм аннан да күбрәк җылылык.

Махсус комлыкларда, коткаручылар кизү торган җирләрдә коену сорала. Суда уеннар оештырмау, балаларны үзләрен генә калдырмау хәерле.

Ялда агулану очраклары да еш була. Бигрәк тә ял урыны итеп экзотик илләрне сайласаң. Роспотребнадзор белгечләре андый илләрдә кайнаган су гына эчәргә тәкъдим итә. Урамдагы ларек, киштәләрдән җилак-җимеш, яшелчә сатып алмаска, алган очракта да аны кайнаган суда юарга киңәш итәлә.

Ахыры 2 нче биттә >

Эшле халык

1 июльгә Казанда эшсезләр сыйфатында 2,5 меңгә якын кеше теркәлгән. Бу сан, узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 1,5 тапкыр кимрәк. Шәһәрнең Мәшгульлек үзәге директоры Тимур Муллин әйтүенчә, 6 ай дәвамында Татарстан башкаласында эшсезләр саны кимү, мәшгульләр саны арту күзәтелә. Шәһәрдә эшсезлек күрсәткече – 0,38%.

Беренче ярты еллыкта мәшгульлек үзәкләренә 5,4 мең кеше (2022 елның шушы ук чорындагы караганда 4 меңгә кимрәк) мөрәҗәгать иткән. Шуның 3,8 меңе (71 проценты) эшкә урнаштырылган.

Эшсезлекнең иң зур күрсәткече сәүдә, сәнәгать, транспорт һәм логистика, мәгариф, персональ хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә күзәтелә. 2022 елдан бирле Казанда эшчеләр саны 643 меңнән 649 меңгә җиткән.

Исегезгә төшерәбез: моңа кадәр Россия Президенты Владимир Путин илдә эшсезлек күрсәткеченең тарихи минимумга җитүе турында белдергән иде.

Бер урында

Татарстанда контракт буенча хәрби хезмәткә җыю өчен рәсми сайт эшли башлады, дип хәбәр итә «Татар-информ».

Яңа ресурста хәрби хезмәткәрләргә тиешле түләүләр, ташламалар һәм гарантияләр турында мәгълүмат урнаштырылган. Моннан тыш, контракт буенча хезмәт итү тәртибе турында бөтен мәгълүмат бер урында җыелган.

Сайтта иң элек контрактының хезмәт хакы турында мәгълүмат күренә. Гражданин контракт төзегән вакытта бер үк вакытта 195 мең сум күләмендәге түләүгә исәп тота ала, ә махсус хәрби операция зонасында айлык түләүләр 204 мең сумнан башлана.

Сайтта шулай ук кире элемтә формасы да эшли: чат-ботка сорау биреп, кызыксындырган барлык сорауларга да җавап алырга мөмкин. Контракт буенча хезмәт итү шартлары турында тулырак мәгълүмат белән heroes-tatarstan.ru сайтында танышырга була.

Чама хисе югалса...

Бурычлылар белән эшләүдә янау, яла ягу һәм куркытуга юл куйган коллекторлык фирмалары хезмәткәрләрен җинаять җаваплылыгына тарту турында законга төзәтмәләр үз көченә кергән. Россия Президенты Владимир Путин тиешле закон проектына кул куйган.

Яңа төзәтмәләр шулай ук банклар һәм микрофинанс оешмалары хезмәткәрләренә дә кагыла. Хәзер бурычны законсыз исуллар (янау, көч куллану, бурычлының үзен һәм гаиләсен кимсету, мөлкәтенә зыян китерү) белән кире кайтару өчен 300000нән 500000 сумга кадәр штраф янный.

Моннан тыш бурычлылар белән эшләүдә законсыз исуллар кулланучыларны 5 елга кадәр мәҗбүри эшләргә җәлеп итәргә яки шундый ук срокка төрмәгә утыртырга мөмкиннәр. Шулай ук законда чама хисен бөтенләй белмәгән коллекторлар өчен чараларны кырысландыруны күздә тоткан пунктлар урын алган. Биредә бурычлыга карата төркемләшеп көч куллану, шулай ук аеруча кыйммәтле мөлкәтен бозу турында сүз бара. Мондый гамәлләргә 10 елга кадәр иректән мәхрүм итү һәм 1 миллионнан 5 миллион сумга кадәр штраф салу каралган.

Һава торышы

Кояшка да тәнәфес кирәк

Чын җәй килде, дип сөенергә дә өлгермәдек, һава торышы тагын көйсезләнергә тора. Синоптиклар, бүгеннән башлап Татарстанда һава торышы бозыла башлаячак, дип фаразлый. Җәйге челлә чигенә, республикага салкыннар килә.

Татарстан буенча Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, бу көннәрдә республикага көньяк-көнбатыштан циклон килачәк. Нәтиҗәдә бүгеннән башлап республикада һава торышы кискен үзгәрәчәк. Көчле җил, яшенле, кыска вакытлы яңгырлар көтелә. Республиканың кайбер районнарында боз яву ихтимал. Көндезге һәм кичке һава температурасының да түбәнәюе көтелә.

Аерым алганда, 11 июль көнне Татарстанда төнлә 19–24, көндез 25–30 градус җылы булачак. 12 июльдә исә төнлә терекөмеш баганалары 11–16, көндез 18–23 градустан да югарырак күтәрелмәячәк. Пәнҗешәмбе көнне дә тотрыксыз һава торышы сакланачак. 13 июльдә төнлә 9–14 градус, көндез 19–24 градус җылы булуы көтелә. Урыны белән кыска вакытлы яңгырлар явачак.

Ялларда да салкынча булачак. Синоптиклар 14–16 июль аралыгында төнлә 10–15, көндез 20–25 градус җылы булачак дип ышандыра. Урыны белән яңгыр явачак.

Шулай да синоптиклар бу салкыннарны вакытлыча күренеш дип атый. Киләсе атна башыннан республикага кабат җылы көннәр әйләнеп кайтачак. КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхадиев сүзләренә караганда, июль аенда һаваның уртача айлык температурасы нормадан

«Татар-информ»

бер градуска югарырак булачак. Айның беренче яртысында республикада уртача 20 градус җылы булачак.

– Быел августта һава торышы климатик нормадан артмас дип фаразлыйбыз. Җәйнең соңгы аенда, гадәттә, 18,3 градус җылы була, 54 мм яңгыр яварга тиеш, – ди белгеч.

Иртәгә – 12 июль – Питрау бәйрәме. Димәк, шартлы рәвештә җәйнең икенче өлеше башлана. Халык сынамышларына ышансаң, бу көнне яңгыр яуса, көзен уңыш начар булачак. Питраудан соң кошлар сайраудан туктый. Хәтта күке дә кычкырмый. Шулай да 13 июль көнне күке тавышы ишетелсә, җәй озын булачак дигән сүз.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Илсур МЕТШИН, Казан мэры:

Без сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча зур эш алып барабыз. Казанлыларның 55 проценттан артыгы көн саен спорт, физкультура белән шөгыльләнә. Яшьләр, балалар һәм профессиональ спортчылар белән генә эшләү җитми. Шәһәрдә «Озак яшәүчеләр уеннары» да үткәрергә кирәк.

ТАТАРСТАНДА – БУРЫЧ ҖЫЮ

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы баш идарәсе быелның 6 аена йомгак ясады. Республика приставлары бурычлылардан 8,2 млрд сум акча җыйган.

Мөлкәткә арест салу >> **7** меңнән артык беркетмә

Арест салынган мөлкәт бәясе >> **3,8** млрд сум

Чит илгә чыгуны вакытлыча тыю >> **174** мең беркетмә

Транспорт белән идарә итү хокукын чикләү >> **2** меңгә якын кеше

Алимент буенча бурыч >> **469** млн сум акча җыелган

Хушлашу чыгымлы

Ел башыннан бирле Татарстанда җирләү хезмәтләренә ихтыяҗ 18 процентка арткан. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, гыйнвардан май аена кадәр барлыгы 1,09 миллиард сумлык җирләү хезмәтләре күрсәтелгән. Бу – узган елдагыга караганда 18 процентка зуррак сан.

Статистика буенча, май аенда күрсәтелгән күләмсез хезмәтләр күләме шулай ук 18 процентка артып, акчага салып исәпләгәндә 253,1 миллион сум тәшкил иткән. Белгечләр билгеләп үткәнчә, шушы чордагы көнкүреш хезмәтләренең 4,4 проценты нәкъ менә җирләү хезмәтенә туры килгән.

Документта билгеләп үтелгәнчә, гыйнвардан май аендагы чорда көнкүреш хезмәтләре күләменең 84,6 проценты 4 төрле хезмәткә – транспорт чараларын, машиналар һәм җиһазларны карау-ремонтлау (36,6%), торак һәм башка корылмаларны төзекләндерү-төзү (34,2%), парикмахер хезмәтләре (9,4%), җирләү хезмәтләренә (4,4%) туры килгән.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЙЕЛЛЕНЧА БАШ ИЮ

Дөньякүләм гигантларның үзара мөнәсәбәтләрен ачыклау процессы үткән атнада дәвам итте. Мөнәсәбәтләр элеккечә кала алмый, әмма аларны өзү дә куркыныч, чөнки глобаль икътисад аркау һәм буй җепләре белән тыгыз бәйләнеп беткән. Зур кризисның аяк тавышы якынайган саен, лидерлар кыйшаеп барган икътисад бинасына терәүләр куярга азаплана.

Вашингтон – Пекин диалогы торган саен актуальләшә. Әле күптән түгел генә АКШның Дәүләт секретаре Блинкен Кытайда булып, үзара мөнәсәбәтләрне җанландырырга омтылган иде. Үткән атна финанс министры Дженнет Йелленның дәвамлы визиты белән тарихка кереп калды. Йелленның Кытай вице-премьеры Хэ Лифэн белән күрешкәндә, туктаусыз баш июен мәгълүмат агентлыклары символик ишарә буларак алгы планга чыгардылар. АКШ матбугаты ук моны дипломатик этикетның бозылуы дип бәяләде. Нәрсә генә булмасын, ике держава бер-берсеннән башка яши алмый. Кытай һәрвакытта да АКШның дәүләт әҗәтенең иң зур өлешен финанслаучы дәүләт булды. Әмма соңгы берничә елда кытайлар Америка облигацияләрен күпләп саталар, кайчандыр триллионны узып киткән бурыч кәгазьләре быелның апрелендә $848,8 миллиардка калды. Пекин барлык облигацияләрне берьюлы сатуга чыгарса гына да АКШның финанс системасында зур тетрәү ясый ала. Әмма Америка мәтәлчеге Кытай җимереклегенә дә китерәчәк, яклар моны икесе дә аңлый. Алай гына да түгел, дөньякүләм финанс каруселе як-якка сибелеп чәлпәрәмә килеп бетәчәк. Йеленның Кытайга визиты менә шул зур мәтәлчекне булдырмау максаты куйды. Кытайда чакта ук ул күп кенә каршылыклар булуга карамастан, ике илнең күпкә тотрыклырак нигездә торуын әйтте. Визит төгәлләнүгә, очрашуларның конструктив булуын игълан итте. Кытайның Синьхуа агентлыгы да АКШ белән Кытайга үзара мөнәсәбәтләр өстендәге караңгы болытларны тарату өчен тырышырга кирәклеген билгеләп үтте.

Зур чайкалыштан сакланган хәлдә, дәүләтләр яңа коалицияләр төзергә, бер-берсенә басым ясауның нечкәрәк ысулларын кулланырга омтыла. Һәркем белә: шундый көн килеп җитәчәк, дәүләтләр мөнәсәбәтләрне көч ярдәмендә ачыклый башлар. Шул көн алдыннан уңайлы диспозиция сайлау бурычы хәл ителә. Кытай белгечләре соңгы көннәрдә Тайвань янында Россия Хәрби диңгез флоты кораблары күренүне Кытай – Россия аркадашлыгы көчәю дип бәялиләр. Американың Финанс министрлыгы белгечләре яшерен рәвештә Гонконгта булып киттеләр һәм ул халыкара финанс үзәген Россиягә каршы санкцияләр кырына куып кертергә омтылалар дигән хәбәрләр бар. Россия хәрби сәнәгате өчен кирәкле чипларны Гонконг аша ала, бу сер түгел.

Кытай компартиясенең тышкы сәясәтне билгеләүче төп чиновнигы Ван И Япония белән Көньяк Кореяны Көнбатыш һәм АКШ белән стратегик союздан чыгып, Күк асты иле белән аркадашлыкка күчәргә өндәде: «Чәчләрегезне күпме генә аксыл төсләргә буямагыз, борыныгыз формасын күпме генә үзгәртмәгез, барыбер европалы да, америкалы да була алмассыз», – диде һәм тамырларның кайда ятуын белергә чакырды.

Россиядә

БЮДЖЕТНЫ КИСӘРБЕЗ, ДЕМОГРАФИК КРИЗИСНЫ НИШЛӘТЕРГӘ?

Россиянең эчке сәясәте Украина конфликты тәэсирендә формалаша. Үткән атнада евро – 100 сумга, доллар 93 сумга җитеп, яңа биеклек яулады. Белгечләр, якындагы көннәрдә сум берникадәр ныгыр, әмма көзгә девальвациянең яңа дулкыны күтәелә, диләр.

Үзәк банк 21 июльдәге утырышта төп ставканы күтәрәчәк, моңа берәү дә шикләнми. Йомшарган сум бюджеттагы ярыкны ярыйсы гына томаласа да, казнага барыбер акча җитми. Финанс министрлыгы бюджетны кисү турында хәбәр салды инде. Елның беренче яртысында дәүләт акчаны планлаштырганнан күбрәк тотты, димәк, икенче яртыеллыкта бераз суган суы суырырга туры киләчәк. Белгечләр алдагы айларда безне өч нәрсә: бюджет чыгымнарының кискен кимүе, төп ставканың күтәрелүе, инфляция үсүе нәтиҗәсендә куллануның азаюы көтүен әйтәләр. Болар берсе дә икътисад өчен күңелле яңалыклар түгел.

Пенсия яшен күтәрү Пенсия фондын дефициттан сакламады. 22 процентлык социаль салымнар түләү дә, чыпчык тезеннән генә булган пенсияләр дә пенсия системасын банкротлык алдына килеп терәлүдән коткармый. Хисап палатасы, Пенсия фондының керемнәре пенсия түләүләренең 54 процентын гына каплый, ди әнә. 5 триллион сум акча җитми. Росстат хезмәт хакларының үсеше турында күпме генә сөенечле рапортлар бирмәсен, эш бирүчеләр һәр хезмәткәр өчен түләгән социаль взнослар планда каралганнан 124 миллиард сумга кимрәк акча биргән. Рәсми статистика белән чынбарлыкның беренче генә чәкешүе түгел бу. Дефицитны казна акчасы белән капларга туры килә.

Демографик кризис яңа рекорд яулый. Пенсия фондының күрсәткечләрендә бу котылгысыз чагылыш таба. Әле генә без саубуллашкан июнь ае балалар саны буенча яңа антирекорд куйды. 1991 елдан башлап теләсә кайсы елның июнь аендагыга караганда 2023 июнендә балалар азрак туган. Белгечләр, вазгыять демографик катастрофага китерә торган, диләр. Саннарны күргән һәркем моны үзе дә аңлый ала. 2020–2022 елларда үлүчеләр саны туучылардан 2 миллионга кимрәк булган. Июнь статистикасы кимү темпларының артачагын вәгъдә итә. Киләчәктә социаль взнослар түләячәк буын дөньяга килергә ашыкмый. Илдә эшче көчләргә бүген үк кытлык. Эшче куллар дефицитын 6–7 миллион таза-сау ир кешенең «силовик»лар сафында булуы, бюрократик аппаратның чүпрәдә кабарган кебек кабаруы да көчәйтә. Болар төзелешкә килеп измә ташымый бит инде. Иртәгесе көнгә ышаныч булмау нәтиҗәсендә балалар туу перспективасын киметүгә дә үз өлешен кертә Көнбатыштагы конфликт.

tatarstan.ru

ЭШЛЕКЛЕ МӘЙДАН

Рәис көндәлеге

Ульян өлкәсе, Алабуга һәм Таҗикстанны нәрсә берләштерә? Җавабы бар: ул – Екатеринбургта узучы «Иннопром – 2023» халыкара сәнәгать күргәзмәсе. Әлеге чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Күргәзмәдә республика стенды да урын алган. Биредә Татарстан сәнәгать предприятиеләренең төп продукциясен тәкъдим иттеләр. Рөстәм Миңнеханов күргәзмәне карады һәм җитештерүчеләр белән аралашты. Рәис күргәзмәдәге башка стендлар белән дә танышты.

Эш кысасында Рөстәм Миңнеханов Ульян өлкәсе губернаторы Алексей Русских белән очрашты. Төбәк башлыклары Ульян өлкәсе стенды янәшәсендә күрештеләр. Шунда ук төбәкнең сәнәгать продукциясен дә карадылар. Аерым алганда, «Соллерс – Атлант» шассие базасында төзелгән ашыгыч ярдәм машинасы игътибарны җәлеп итте.

– Безнең сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне арттыру өчен мөмкинлекләр зур, – диде Рөстәм Миңнеханов, төбәкләрнең үзара күршеләр булуына ишарәләп.

Моның белән Алексей Русских та килеште. Ул Татарстан делегациясен Ульян өлкәсенә эш сәфәренә чакырды. Яклар ике арада елга маршрутларын булдыру турында да фикер алышты.

Халыкара чарадагы тагын бер мөһим очрашу: «Иннопром – 2023»тә Рөстәм Миңнеханов Таҗикстан Республикасының сәнәгать һәм яңа технологияләр министры Назар Азиз Савзали белән күреште. Министр Рәискә Таҗикстан белән хезмәттәшлекне үстерүгә күрсәткән игътибары өчен рәхмәт белдерде. Яклар нефть химиясе өлкәсендә бергәләп эшләү турында фикер алышты. Татарстан белән Таҗикстан медицина өлкәсендә дә, аерым алганда, медикаментлар белән тәэмин итүдә, элемтәләрне ныгытырга мөмкин.

«Иннопром – 2023»тә Татарстандагы заводны да эшләтеп җибәрделәр. Әлеге чарада күргәзмәгә килгән Россия Премьер-министры Михаил Мишустин һәм Рөстәм Миңнеханов катнашты. Татарстан стендында «Соллерс» компаниясенең «Алабуга» махсус икътисадый зонасында двигательләр җитештерү заводын эшләтеп җибәрү тантанасы узды.

Билгеле булганча, «Соллерс»ның двигательләр җитештерү заводы 2015 елда «Соллерс» ГАҖ һәм «Форд Мотор Компани»ның уртак предприятиесе буларак эшли башлады. Биредә 2019 елга кадәр «Форд» автомобильләре өчен двигательләр җыйдылар.

Бүген исә завод сәнәгать линиясенең 95 проценты автоматлаштырылган. Сәнәгать куәте елына 50 мең данә двигатель тәшкил итәчәк дип көтелә. Бу – илдә эшне башыннан алып ахырына кадәр башкарып чыгу мөмкинлеген тәэмин итүче тәүге сәнәгать мәйданы. Биредә автомобиль сәнәгате һәм башка тармаклар өчен двигательләр җыячаклар.

– Барыгызга да, Татарстан җитәкчелегенә, Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгына әлеге эшне оештыруыгыз өчен рәхмәт белдерәм, – диде Михаил Мишустин.

Россия Хөкүмәте җитәкчесе 2007 елда «Алабуга» махсус икътисадый зонасын эшләтеп җибәрүдә катнашуын да искә алды. Аның әйтүенчә, бүген сәнәгать мәйданы ышанычлы рәвештә үсә.

Белешмә

Быел «Иннопром – 2023» халыкара сәнәгать күргәзмәсе 10–13 июльдә уза. Ул Екатеринбургта 2010 елдан бирле ел саен үткәрелә. Оештыручылар әйтүенчә, быел аның эшендә 700 компания катнашачак. Бу – рекордлы сан. Күргәзмәнең партнеры булган Белоруссиядән генә дә 100дән артык предприятие вәкилләре килгән.

ЯЛДАН АРЫМА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

АКЧА. Ялга үз автомобиле белән җыенган кешеләргә киңәш шул: сәяхәткә чыгуыгызны кичке якка планлаштырыгыз. Бердән, балагыз машинада йоклап барачак, сезгә комачау итмәячәк. Икенчедән, төнге сәгатьләрдә түләүле трассадан узу хакы да арзанрак булачак.

Кунакханәгә урнашуны да иртәнге сәгатьләргә яисә көннең икенче яртысына калдырырга мөмкин. Шул рәвешле кунакханәдә артык бер төн өчен түләмәячәксез. Кунакханәләрдә еш кына балалар өчен ташламалар карала. Әйтик, билгеле бер яшькә кадәр балаларга кайбер кунакханәләрдә куну бушлай. Кайберләрендә өстәмә ятак өчен өстәмә акча да сорарга мөмкиннәр.

Белгеч сүзе

Наталья НАУМОВА, гаилә һәм балалар психологы:
– Бергә ялга җыенганда, ата-аналарга балаларның кызыксынуларын исәпкә алмый чара юк. Мондый ял бөтен кешегә дә ошаячак. Өч яшькә кадәр балалар төрле чараларда катнашса, батут, аттракционнарда күңел ачса, яшүсмерләр белән алай гына булмый. Алардан нәрсә эшләргә теләүләре хакында алдан белешеп кую хәерле. Балалар «безнең фикер белән дә санлашалар» дип уйларга тиеш. Балаларыгызның көндәлек режимына да игътибар итегез. Әйтик, йокы вакыты белән ашау вакыты ял иткәндә дә элеккегечә булырга тиеш. Гомумән, бергә ял иткәндә берләшергә кирәк. Әрләшмәскә, бер-береңне тыңларга, ярдәмләшергә.

Ялга аптечка җыябыз

Пластырь, температураны төшерә торган дарулар (составында парацетамол, ибупрофен булганнар), антигистамин дарулар (аллергиядән саклану өчен), тоз-глюкоза эремәсе (эчәк инфекциясеннән, кызу сукса), хушландыргыч дымлы салфетка.

«Авиасейлс» хезмәте мәгълүматларына нигезләнеп

Лаеклы һәм мөһим җиңү

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Шәүкәт Мирзиёевны Үзбәкстан Республикасы Президентын сайлауда җиңүе уңаеннан котлады.

«Лаеклы һәм бик мөһим җиңүегез уңаеннан иң җылы котлауларны кабул итегез, – диелгән котлауда. – Ватандашларыгыз Сезгә дәүләтегезнең язмышын һәм үзләренең киләчәген ышанып тапшырган. Бу – бүгенге дөньяда тотрыксызлык хөкем сөргән бер мәлдә аеруча мөһим. Президент сайлавында җиңүегез, көчле, тәҗрибәле дәүләт әһеле, киләчәкне алдан уйлап эш итүче, талантлы сәясәтче буларак, какшамас абруегызны тагын бер кат дәлилли. Россия белән Үзбәкстанның дустанә мөнәсәбәтләре кысасында Татарстан һәм Үзбәкстан арасындагы күпкырлы, үзара файдалы хезмәттәшлекнең алга таба да нәтиҗәле булачагына ышанам».

Татарстан Рәисе Үзбәкстан Президентына республиканы үстерү максатында ниятләнелгәннәрне тормышка ашыру өчен саулык-сәламәтлек, көч-куәт теләде.

САУБУЛЛАШУ АЛДЫННАН ОЧРАШУ

Төркиянең Казандагы Генераль консулы Исмәт Эрикан Татарстанда эшен төгәлләли. Дипломат белән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин очрашты.

Фәрит Мөхәммәтшин Генераль консулга республикадагы эше өчен рәхмәт белдереп, Россия белән Төркия арасында сәүдә-икътисадый, мәдәни һәм гуманитар элемтәләрнең булдырылуын, Татарстан белән Төркия арасында дустанә мөнәсәбәтләрнең, шул исәптән парламентара элемтәләрнең ныгытылуын билгеләп үтте.

Парламент Рәисе сәүдә-икътисадый хезмәттәшлекне көчәйтүгә аерым тукталды. Гадәти булмаган шартларга, бик күп санкцияләр кертелүгә карамастан, республиканың күп юнәлешле икътисады эзлекле төстә үсүен дәвам итә. Татарстан төп социаль-икътисадый күрсәткечләр (төбәкнең тулай продукты, сәнәгатьтә җитештерү индексы, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме, төзелеш темплары һ.б.) буенча алдынгы сафларда бара.

Исмәт Эрикан, үз чиратында, Генераль консуллыкның проектлары һәм башлангычларын гамәлгә ашыруга төрле яклап ярдәм иткән өчен, республика җитәкчелегенә рәхмәт белдерде. «Узган 4 ел сәяси яктан да, социаль-икътисадый яктан да гади генә булмады, – диде ул. – Әмма барлык башлангычларыбызда һәрвакыт Татарстан парламентчыларының ярдәмен тоеп киләбез».

Эрикан әфәнде шулай ук Төркия һәм Россия арасындагы элемтәләр кысасында нәкъ менә Татарстан белән хезмәттәшлеккә аерым зур игътибар ителүен билгеләп үтте. Россия икътисадына инвестицияләрнең дүрттән бер өлеше чамасының Татарстанга туры килүен генә билгеләп үтү дә җитә. Шул ук вакытта Татарстан инвестицияләренең Төркия икътисадына җәлеп ителү күләме дә арта, уртак предприятиеләр ачыла.

Исегезгә төшерәбез: Исмәт Эрикан 2019 елдан бирле Төркиянең Казандагы Генераль консулы вазыйфасында эшләде. Эрикан әфәнде, 1996 елда Казанда Төркиянең Генераль консуллыгы ачылганнан соң, 12 нче Генераль консул булды. Генераль консуллык Татарстан башкаласында ачылган чит дәүләтнең тәүге дипломатик вәкиллегенә әйләнде.

ЧҮП ӨСТЕНӘ – ЧҮМӘЛӘ

Әйләнә-тирәлек

Татарстанда яшәүчеләр әйләнә-тирәгә битараф түгел. Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына ел башыннан халыктан 7 мең мөрәҗәгать килгән. Аларның 77 проценты чүплекләргә бәйле.

Соңгы елларда республикада чүп чыгару мәсьәләсе дә аксый. Атналар буе чүпне алып китмәгән очраклар да бар. Әлеге һәм экологиягә бәйле башка проблемалар хакында Татарстанның төбәкләр белән идарә итү үзәгенең Казандагы проект офисында узган утырышта сөйләштеләр.

Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министрының беренче урынбасары – әйләнә-тирәне саклау өлкәсендә төп дәүләт инспекторы Илнур Гобәйдуллин әйтүенчә, соңгы ярты елда чүпкә бәйле проблемалар катлауланган.

– Халык көнкүреш калдыкларын вакытында алып китмәүләренә зарлана. Ел башыннан министрлыкка чүп җыю буенча төбәк операторларының эшчәнлегенә бәйле 300 зар килде. Күбрәк республиканың төньягында яшәүчеләр мөрәҗәгать итә. Чүпләрне җыю мәйданчыклары СанПиН таләпләренә туры килми. Төбәк операторларының эшчәнлеген район башкарма комитетлары үз контроленә алсын иде, – ди баш инспектор.

Экологлар соңгы биш елда Чулман, Минзәлә, Зәй һәм башка елгаларда суның сыйфаты үзгәргәнен дә ачыклаган.

– Бу чистарту корылмаларының сыйфатсыз эшенә бәйле. Сулыклар нигә бетәме? Күп җирләрдә йорт төзергә рөхсәт бирелгән, әмма андагы сулыкларны саклау турында берни әйтелмәгән. Шулай итеп, төзелеш аркасында чишмәләр дә юкка чыга. Төзи башлаганда берәү дә бу җирдә су чыгу-чыкмавын тикшереп тормый, – ди Илнур Гобәйдуллин.

Баш инспектор, халык һаваның сыйфатыннан да риза түгел, ди. Казанның «Салават Күпере» микрорайоны, Киров һәм Мәскәү, Авиатөзелеш районнары һәм Залесный бистәсендә яшәүчеләр атна саен сасы искә зарлана икән. Узган ел ахырыннан мөрәҗәгатьләр кинәт арткан. Инде бу ел башыннан министрлыкка шул уңайдан 400 зар килгән. Экологлар «Салават Күпере»ндә һава чисталыгын контрольдә тоту өчен күчмә лаборатория дә алып килеп куйган иде. Әнә шуның нәтиҗәләренә карап, биредә һавадагы формальдегид һәм күкерт газының шактый артып китүен күзәтәләр икән. Моның сәбәпчесе дә билгеле: ул – Химическая урамында урнашкан полигон. Утырышта әлеге полигон өчен җавап бирүче оешма җитәкчесе дә бар иде. Аларга формальдегид һәм күкерт газы күләме артуга бәйле рәвештә күзәтчелек органнары тарафыннан табигатькә китергән зыяннары өчен 360 мең сум күләмендә штраф та салынган инде. 2020–2021 елларда һавага пычрак матдәләр таратканнары өчен 18 млн сум күләмендә штраф салынып, әлегә суд эшләре дәвам итә. Бу полигоннан аккан пычрак Коры елгага да зыян китергән. 2024 елда полигонны куллану вакыты чыга икән. Шуннан соң бу урын бөтенләй юкка чыгарылачак.

Чүпне вакытында түкмәсәң, һава пычрана, кеше сасы ис исни. Чүплекләргә күсе-тычканнар ияләшеп, төрле авырулар китереп чыгарырга да мөмкин. Республикада яшәүчеләр чүпне көн саен алып китүләрен сорый. Ә менә Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгин әйтүенчә, бу бик чыгымлы булачак. Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская исә кешеләрнең хокукларын яклый. Белгечләр шуңа да чүп проблемасын хәл иткәндә, һәр өлкәнең фикерен тыңларга кирәк, диләр.

– Безгә социаль челтәрләр аша чүплекләргә дә, һава сыйфатына да зарланып еш мөрәҗәгать итәләр. Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Түбән Кама, Яшел Үзән, Лаеш, Бөгелмә, Әлмәт, Алабуга районнарында яшәүчеләр еш зарлана. Быел «Инцидент менеджмент» системасына экологиягә бәйле 203 мөрәҗәгать килде, – ди Сәрия Сабурская. – Чаллыда яшәүчеләр төтен исенә зарлана. Мондый исне Минзәләдә яшәүчеләр дә сизгән. «Салават Күпере» микрорайонында исә төннәрен сасы ис тарала, дип хәбәр иттеләр. Экология кешенең сәламәтлегенә һәм тормыш сыйфатына йогынты ясый. Әле безгә бу өлкәдә эшлисе дә эшлисе.

Автор фотосы

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОСМОНАВТ, РОССИЯ ГЕРОЕ АНТОН ШПАКЛЕРОВ:

«АЙГА ДА МЕНӘР ИДЕМ»

Очрашу

Космонавтлар әзерләү үзәгендә Татарстаннан килгән делегация белән очрашырга Антон ШПАКЛЕРОВ килә дигәч, аеруча сөендек. Шулай булмыйни! Илебез кинотеатрларында «Вызов» фильмы шау-шу тудырган мизгел бит, ә ул анда берьюлы ике рольне алып бара: актер да, космонавт та. Сөйләшеп алырга менә дигән җай чыкты дигән сүз. Җитмәсә, бик гади, ихлас әңгәмәдәш.

Космонавт, Россия Герое Антон Шпаклеров (уңда) «РКК «Энергия» үзәгенең баллистика бүлеге җитәкчесе Рафаил Мортазин белән очрашуда.

:: Галәм киңлекләрендә дөньяда беренче тапкыр нәфис фильмга төшү эзсез генә үтмәгәндер дип уйлыйм. Нинди хисләр кичердегез?

– Мин үзем дә кинога беренче тапкыр төштем. Ә аны нәкъ менә космонавтлар стихиясендә, галәмдә төшерү барыбызга да бик ошады. Дөресен генә әйткәндә, минем өчен көтелмәгәнрәк вакыйга булды бу. Безне озату үзе үк зур шоуга әйләнде. Хәтерлисездер, Байконурга искиткеч күп журналистлар, белгечләр җыелган иде. Мондый игътибарны беркайчан да күргәнем булмады.

:: Актер – сезнең өчен бөтенләй башка һөнәр, ниндидер кыенлыклар килеп чыктымы?

– Булгалады. Беренчедән, текстны яттан өйрәнү авыррак булды. Мин моңа күнекмәгән бит. Камерага сөйләгәндә гадәттә үз сүзләребезне сөйлибез яки экрандагы әзер «йөгерек юллар»ны укыйбыз. Ә монда яттан өйрәнергә кирәк. Җитмәсә, шигырь дә түгел бит әле ул, проза. Икенчедән, дубльләр артык күп булды. Хәтта бер җөмләне унар тапкыр әйтергә туры килде.

:: Галәмгә башка һөнәр ияләре белән очу ниндирәк тәэсир калдырды?

– Юлия Пересильд белән Клим Шипенко Космонавтлар әзерләү үзәгендә тиешле әзерлек үттеләр. Тизләтелгән режимда, әлбәттә. Әмма күнегүләр, дәресләр җитәрлек булды. Алар теләсә нинди вазгыятьтә скафандр белән эш итәргә өйрәнделәр. Диңгездә исән калу программасын үттеләр. Станциядә ашарга әзерләү серләренә төшенделәр. Кыскасы, 4 ай ярымга сузылган өйрәнүләр булды. Вакытны бик кыскарттылар, әлбәттә. Гадәттә туристлар алты, кайчагында тугыз ай буена күнекмәләр алалар.

:: Яңа «табадан төшкән» космонавтлар өчен нәрсәне эшләргә ярамый дигән берәр исемлек бармы?

– Иң мөһиме, алар нәрсәне эшләргә ярый икәнлеген белергә тиешләр. Ә калганнарына тыкшынмаска, кагылмаска гына кирәк. Тик шуны истән чыгарырга ярамый: Юлия белән Клим галәмгә билгеле бер вазыйфаларны үтәргә менделәр бит. Мин беренче тапкыр космоска бортинженерсыз очтым. Мондый очракта командирга ярдәм бик кирәк. Алар янында минем кулым җитмәгән рычаглар бар иде. Берәр хәл килеп чыкса, клавишларга тиз генә басарга кирәк, бу вакыт эчендә мин креслодан торып та өлгермәс идем. Шуңа күрә өстәмә пульт эшләдек. Ул Юлия карамагында булды. Команда булуга, ул пультны миңа бирергә тиеш иде. Клим басымны тигезләү клапаннары өчен җавап бирде.

:: Галәмдә кино төшерү нигә кирәк булды дип уйлыйсыз?

– Минемчә, бу кинопроект Галәмне үзләштерү тарихын искә алу, халыкны, бигрәк тә яшьләрне илһамландыру өчен кирәк дип уйлыйм. Юрий Гагарин космоска очкач та, илебездә бик зур күтәрелеш булды. Ул бик озак елларга барды. Үзгәреш елларында исә космос темасы бөтенләй күз уңыннан төшеп калды. Интернет барлыкка килгәч, социаль челтәрләрдә мәгълүматлар күбәйде, әмма халыкны элеккеге кебек кызыксындыра алмады.

:: Пересильд белән Шипенконы космонавт буларак ничек бәялисез?

– Алар үз эшләрен шундый шартларда да искиткеч башкардылар. Станция бит ассистентлар, тагын әллә кемнәр йөгереп йөргән кино төшерү мәйданчыгы түгел. Зур эшләрне дә, вак-төяген дә үзеңә эшләргә туры килә. Мин дүрт тапкыр галәмдә булдым. Бик күп кешеләр белән очрашырга туры килде. Зур ышаныч белән әйтә алам: Юлия белән Клим, һөнәрләрен алыштыра калсалар, космонавт була алырлар иде.

:: Актер буларак, үз ролегез ничек килеп чыкты дип уйлыйсыз?

– Мин сценарий буенча исемсез космонавт булырга тиеш идем. Ә Юлия миңа эндәшергә тиеш булып чыкты, чөнки төшерү барышында үзгәрешләр дә пәйда булды. Нәтиҗәдә миңа Антон Шпаклеровны, ягъни үз-үземне уйнарга туры килде. Әйтергә кирәк, бу минем өчен шактый җиңеллек тудырды.

:: Җиңеллек дигәннән, фильмда сюжет космик станциядә үткәрергә туры килгән хирург операциясе тирәсендә бара. Сез азмы-күпме бу эшләр белән таныш идегезме?

– Һичшиксез. Без Космонавтлар әзерләү үзәгендә очыш алдыннан медицина буенча да әзерлек үтәбез. Станциядә җиһазлар бик күп. УЗИ аппаратларыннан башлап йөрәкне эшләтеп җибәрүче дефибрилляторга кадәр бар. Безне бу техникалардан файдаланырга өйрәтәләр. Күп очракта телемедицина, табиблар белән онлайн консультацияләр ярдәмгә килә.

:: Антон Николаевич, белгәнебезчә, сез космонавтлар отрядында эшчәнлегегезне туктаттыгыз. Күңел галәмгә тартыламы?

– Әлбәттә. Айга менеп төшәрлек тә көч-куәт бар кебек. Әмма космос ул шундый өлкә – барысын да вакытында эшләргә, характерны үзгәртергә, мөмкинлекләрне белеп чамаларга кирәк.

:: Беренче каналда «Космос тарихлары» исемле тапшырулар алып баруыгызны да шул үзенчәлекләрнең берсенә кертергә кирәктер?

– Әйе. Мин тамашачыларны галәм темасы белән якыннанрак таныштырырга телим. Галәмгә очу өчен нинди әзерлек үтәргә, космик корабльләрдә гадәттән тыш хәлләр килеп туса нишләргә дигән сорауларга җавап бирәм, яңалыклар белән дә таныштырып барам. Һәр тапшыру кызыклы, яшьләрдә кызыксыну уятырлык булсын дип тырышам.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Белешмә

- Антон Шпаклеров – космонавт, техник фәннәр кандидаты, Россия һава-космик көчләре полковнигы.
- 2003 елның 29 маенда космонавтларны сайлап алу буенча ведомствоара комиссиясе карары белән космонавтлар отрядына кабул ителә.
- 2023 елның 14 мартында «Роскосмос» дәүләт корпорациясенең космонавтлар отрядында эшчәнлеген тәмамлый. Хәзер ул – Юрий Гагарин исемендәге космонавтлар әзерләү үзәгендә идарә начальнигы урынбасары.
- Антон Шпаклеров 4 тапкыр очыш ясый. Барлыгы 709 тәүлек 8 сәгать 4 минут галәмдә була.
- 3 тапкыр чыгып, барлыгы 21 сәгать 39 минут ачык космоста була.
- Космонавтлар отрядында 7229 көн эшли.

ФАТИРНЫ – ЛИЗИНГКА

Торак мәсьәләсе

Россия Үзәк банкы ипотекага алмаш тәкъдим итә. Ул да булса, торакны лизингка бирү тәртибен җайга салмакчылар. Бу – ипотекага беренчел кертемгә акчасы җитмәүчеләргә яки ниндидер сәбәпләр аркасында кредит рәсмиләштерә алмаучыларга шәп мөмкинлек, ди белгечләр. Чит илләрдә мондый тәҗрибә күптән гамәлдә икән инде. Торакка лизинг отышлымы? Бу сорауга «ВТ» хәбәрчесе җавап эзләде.

«Татар-информ»

«Бөтен халыкның фатир сатып алырлык яки ипотека түләрлек акчасы булса, тулай тораклар калмас иде», – ди Казанда яшәүче Нәзилә Гарифуллина. Ул гаиләсе белән 30 елга якын тулай торакта яши.

– Балалар бакчасында пешекче булып эшлим. Ирем – машина йөртүче. Тулай торакта ике бала үстердек, хәзер аларның үз тормышы. Башта ипотеканы ай саен түләп бара алмабыз, дип курыктык, бүген исә картлык көнендә мондый йөк кирәкме икән, дибез. Фатирда яшәүчеләр торак шартларын болай да гел яхшыртып тора: кечкенәсен саталар да зуррак түбә алалар. Ә менә тулай торактан күченеп китү авыррак. Безнең ише тулай торакта яшәүчеләргә ярдәм чарасы уйлап тапсыннар иде, – ди Нәзилә Гарифуллина.

Фатир сатып алу кебек зур адымга барудан куркып торучыларга лизинглы торак программасы ярдәм итәргә мөмкин, ди белгечләр. Чөнки бүген үк беренчел кертемнәрсез яңа түбә астына күченеп, аны акрынлап кына түләп барып булачак. Иң элек «лизинг» сүзенә ачыклык кертик. Ул – соңрак сатып алуны күздә тотучы аренда. Милек кенә түгел, автомобиль, җиһазны да лизингка рәсмиләштерергә мөмкин. Торак турында сөйләгәндә, ул болай эшли: иң элек фатирны арендага бирүче белән биредә яшәргә теләүче арасында озак вакытка исәпләнгән килешү төзелә. Фатирда яшәүче кеше аренда бәясе белән беррәттән, милек бәясен дә түләп бара. Тиешле сумма туплангач, торак яңа хуҗага күчә. Ике якның берсе кире уйласа, аренда хакыннан кала, лизинг килешүе буенча түләнгән акча кире кайтарылачак.

Ипотеканы банк рәсмиләштерсә, соңгысын фәкать юридик затлар, ягъни лизинг компанияләре генә эшли ала. Гади арендадан тагын бер аермасы: син нәкъ менә үзең теләгән фатирга лизинг килешүе рәсмиләштерә аласың. Башта күңеленә хуш килгән торакны табасың, ә аннары документлар рәсмиләштерәсең. Аренда торагы базарында исә булганнары арасыннан гына сайларга туры килә.

Торакны лизингка алу тәртибе эшләп киткәнче вакыт кирәк булачак, ди башкаладагы милек агентлыгы белгече Андрей Тимченко.

– Иң элек ышанычлы лизинг компанияләре булырга тиеш. Кредит оешмалары тораклы булырга теләүчеләрне энә күзе аша үткәрә. Шуңа күрә банк белән сатып алучы арасында ышанычлы хезмәттәшлек урнаша. Ә юридик зат торакны озак вакытка арендага алып торучыны ярык тагарак янында утыртып калдырмас дип кем ышандырып әйтә ала? Дөрес, әлеге программаның өстенлекле яклары да бар. Лизинг торагыннан, ул әлегә синеке булмаса да, беркем куып чыгара алмый, – ди белгеч.

САН

2022 ел нәтиҗәләренә караганда, республика ипотека үсеше күрсәткече буенча, икенчел торак базарын да кертеп, ил төбәкләре арасында **11** нче урынга чыккан. «РИА Новости» үткәргән тикшерүдән ачыкланганча, быелтыр Татарстанда яшәүче эшкә сәләтле **1** мең кешегә **25,5** ипотека рәсмиләштерелгән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, быел республикада әлеге күрсәткеч **25,8** процентка арткан. Ипотека кредитының уртача күләме **3,54** миллион сум тәшкил иткән. Чагыштыру өчен: Мәскәү **84** ил төбәге арасында – **80** нче урында.

«Газпромбанк» хезмәткәре Алсу Нуриева фикеренчә, лизинг ипотеканы алмаштыра алмаячак.

– Россиядә фатирга лизинг программасы 2011 елдан бирле гамәлдә. Тик ул халык арасында зур кызыксыну уятмады, – ди белгеч. – Автомобильгә лизинг программасы белән дә шул ук хәл. Бүген әлеге программадан нигездә оешма-предприятиеләр һәм эшкуарлар гына файдалана. Ә гади халык кулдагы килешү нигезендә үзенеке булып саналган милеккә акча түләп баруны кулайрак күрә. Торак арендасы һәм лизинг бәяләрен кушсаң, ул ипотека хакыннан әллә ни аерылмый. Шуңа күрә дәүләт әлеге программага ярдәм итәргә алынган да инде. Аның тәгаен шартлары соңрак билгеле булачак, – ди белгеч.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов әйтүенчә, торак базарына төрлечә ярдәм итәргә тырышулары аңлашыла.

– Иң беренче чиратта, беренчел торак базарын саклап калырга тырышалар. Чөнки бүген ташламалы ипотека аркасында, бу өлкәдә вазгыять бик нык кискенләште. Бәяләр үсте. Ә халыкның торак сатып алырга акчасы юк. Якын арада сату-алулар саны артмаса, милек базарында, бигрәк тә беренчел торак базарында кризис башланырга мөмкин, – ди ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең тәрбия эше һәм социаль эш буенча проректоры **Жукова** Ирина Викторовнага **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәре Совет районының «181 номерлы күппрофильле мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Айзатуллова** Фидария Мирзаҗан кызына, «Казан шәһәренең сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен 7 номерлы мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Аляева** Роза Әзгать кызына, Казан шәһәре Вахитов районының «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 18 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Бәдриева** Рина Ринад кызына, Казан шәһәре Идел буе районының «129 номерлы рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Габдрахманова** Динә Гыйматдин кызына, Казан шәһәре Мәскәү районының «Татар телендә белем һәм тәрбия бирелә торган 372 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең физик культура буенча инструкторы **Галчушкина** Светлана Владимировнага, Казан шәһәре Вахитов районының «96 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Гыйниятуллина** Венера Илдар кызына, Казан шәһәре Вахитов районының «12 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Гусева** Татьяна Анатольевнага, Казан шәһәре Яңа Савин районының «31 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Мозаффарова** Лилия Равил кызына, Казан шәһәре Мәскәү районының «75 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Помыкалова** Лариса Петровнага, Казан шәһәре Мәскәү районының «2 номерлы лицей-интернат» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең информатика укытучысы **Сафиуллин** Илшат Ирек улына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Документлар белән тәэмин итү идарәсе контроль һәм эш башкару бүлеге әйдәүче белгече **Әгъләмҗанова** Венера Солтан кызы, республиканың авиация сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «ЭНИКС» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Нагибин** Игорь Владимировичны, «ЭНИКС» акционер җәмгыятенең юнәлеш баш конструкторы **Якупов** Илдар Рәис улы, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри эшчәнлектәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының оештыру ягыннан үсеш бүлеге әйдәүче белгече **Сәгъдиева** Эльмира Тәлгать кызы, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең гражданнар һәм эшкуарлар хокуклары кафедрасы доценты **Шаһвәлиев** Рөстәм Минзаһит улы, халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе **Шәйхетдинова** Любовь Николаевна, банк системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АК БАРС» акционер коммерциячел банкы (гавами акционер җәмгыяте) Инвестиция бизнесы дирекциясенең Капитал һәм синдикацияләр базары идарәсе вексель юнәлеше җитәкчесе **Шакирова** Суфия Фуат кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медал**е белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы **Гыйлаҗиев** Роберт Фәйзи улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клуб системасы» (Район Мәдәният йорты) муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе **Царегородцева** Марина Анатольевнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Азнакай районы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Әхмәтов** Рафис Галимҗан улына, Кукмара районы кулланучылар кооперативы советы рәисе **Зарипов** Илхаметдин Архаметдин улына, «Вятка» кулланучыларның сату авыл хуҗалыгы кооперативы склады мөдире **Мәхмүтова** Ирина Борисовнага, «Рассвет» кулланучыларның катнаш авыл хуҗалыгы кооперативы рәисе **Миңнуллин** Флюр Хәйдәр улына, «Актаныш» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Нургалиев** Фарил Фидаил улына, «Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасының җәмәгать туклануы бүлеге башлыгы **Спичкова** Лилия Әмир кызына, Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекциясе Казан территориаль органы башлыгы **Егорова** Марина Ивановнага, «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционер җәмгыятенең 1 нче ашханәсе директоры **Лаврентьева** Марина Александровнага, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Туклану комбинаты директоры **Хөсәенов** Нәзыр Фахри улына, «Үзәк кулланучылар җәмгыяте» кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе **Зиннәтуллин** Марат Хәбир улына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча 5 номерлы суд участогы җәмәгать судьясы **Җамалетдинова** Земфира Рәшит кызына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТЭНЕРГОСБЫТ

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 N 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

Алга

Мәзәк сөйләгәндә иң ахырдан жираф көлә, чөнки аның муены озын, тиз генә барып җитми, диләр бит. Юмор ул һәрвакыт үз вакытында барып җитми икән. Кайберләре еллар үткәч кенә аңлашыла башлый.

Гомер буе авылыннан чыгып карамаган бер адәм күршесенә утырып Казанга юлга чыккан. Район чигендә бик матурлап нинди дә булса билге куялар бит. «Хәерле юл!» дигән язуы да була. Ә икенче район башланган урында «Рәхим итегез!» дигәне каршылый. Әнә шундыйрак җиргә җиткәч, теге кеше җан сагышы белән: «Прощай, Башкирия!» – дип сөрәнләгән. Башкортстан бетми әле анда, Татарстанга чыкканчы тагын ике район үтәсе бар. Менә шушы хәлне мәзәк итеп сөйлиләр иде. Кемнәрдер хәтта көлә дә. Ә миңа, гомер буена илне айкап йөргән кешегә, кызык тоелмый. Авылыннан чыкканы булмагач, юлны белми бит инде. Кая барганын да аңламый, хәтта Актаныште төшереп калдырсаң да: «Казан шушы икән», – дип йөрергә мөмкин. Офыклары чикле, карашы тар… Шул мәзәкне хәтерләп, менә хәзер генә елмаеп куйдым. Егерме елдан соң…

Авылдан чыкмый яшәгән кешенең шулай кылануы бик табигый инде, бер карасаң. Бәләкәй чакта үзебез дә шул чамарак идек бит. Офыклары чикләнгән кешенең дөньяга карашы да үзенчәрәк була, чөнки ул үз карашы, үз хыялы биргән мөмкинлекләр чигендә генә яши ала. Бик кечкенә вакытта, мәсәлән, саннар тәртибе болайрак булып күренә иде: бер-ике-өч дип унга кадәр җитәсең дә аннан вакланып тормыйсың, ун – егерме – утыз – кырык – илле – йөз дип китәсең…

География дә бик гади генә кебек. Район үзәгенә кадәрге авылларны беләсең инде, аларны үз тәртибендә саныйсың. Ә аннан соң… Минем өчен ул менә болайрак тоела иде: Яркәй – Уфа – Казан – Мәскәү – Берлин – Америка. Азрак үсә төшкәч кенә ачыкланды: Мәскәүдән соң шундук Берлин башланмый, араларында Харьков та бар икән әле, минем бабай шунда немесләр белән сугышканда үлеп калган.

Тора-бара Африка, Кытай дигәннәрне ишеттек. Африка Җир шарының иң аскы ягында, караңгыда, шуңа анда яшәгән кешеләрнең тәне кап-кара. Ә Кытай, киресенчә, Җирнең иң өске өлешендә, күк гөмбәзе астында. Аларның тәннәре сап-сары икән. Мин ул сарылыкны көзге каен яфрагы кебегрәк күз алдына китерәм һәм сәбәбен кояш ныграк кыздыргангадыр дип гөманлыйм.

Бер карасаң, адәм баласы кызык, һәр нәрсәне үз мантыйгына яраклаштыра. Шул мантыйгы буенча үз дөньясын төзи. Шуңа дөнья артык зур түгел, ә адәм акылына сыеп бетәрлек дәрәҗәдә генә була. Бу чиксезлекнең без кабул итә алган өлеше генә – дөнья, калганы – бушлык, билгесезлек яки бөтенләй юк…

Бераз зурайдык инде, бөтен нәрсәне дә аңлый башладык. Тарих дөреслеге ачылды. Революциягә кадәр халык бик интегеп яшәгән икән. Хәерчелектә җәфа чиккән, ач-ялангач булган. Надан булган. Соңгысына мин нык ышанам, аның мисалы күз алдында – минем әби. Ул бөтенләй артта калган, хәреф тә танымый. Искечә генә белә инде, тик анысы чутланмый – иске хәрефләр белән яңа тормыш төзеп булмый ич. Тарихны да белми. Бәхәсләшкән була әле шул көенә, Николай заманында кызыл билле перәнникләр бар иде, кызыллар килгәч тә бик рәхәт күрсәтмәделәр, дигән була. Чи надан инде, короче…

Ә без, тарих дәресе укыгач, бөтенесен дә беләбез. Патша заманнарында халык бик изаланып яшәгән, аларны Ленин гына рәхәткә чыгарган. Шуңа аны зурлыйлар да. Революция, Гражданнар сугышы, ачлык, Бөек Ватан сугышы… Шул рәвешле, тормыш акрын гына җайлана барган. Хәтта өй түбәләренә карап та әйтеп була: башта саламнан япканнар, аннары – такта, аннан – шифер, хәзер хәтта калай белән ябучылар да бар… Элек йөкне кул арбасы белән ташыганнар, аннан – ат белән, хәзер менә машина-тракторлар ташый… Әти-әниләр үзләре дә бит инде башта үлән ашаганнар, аннан – алабута, арыш икмәге, хәзер – бодай күмәче. Нәрсәгә генә карасаң да, тормышның алга баруын, яхшыруын күрсәтеп тора. Менә шуларны күреп яшәгәч, коммунизм дигән нәрсәнең кайчан да бер килеренә шикләнерлек тә түгел иде.

Гомумән, кешелек үсештә бит инде ул. Башта кыргыйлар яшәгән, аннан ыру-кабиләләргә берләшкәннәр, колбиләүчелек, феодализм, капитализм… Тормыш шартлары да яхшыра барган. Менә шуларны уйласаң, без алга барабыз бит инде. Яшәгән саен, тормыш яхшырак була бара. Алга бару ул – яхшылыкка, яктылыкка атлау. Шулай тоела иде.

Сөңге күтәреп мамонт артыннан чапкан борынгы кешене күз алдына китерә аласызмы? Чаба ул. Аягына чыра кадалса да, сөңгесе сынса да, эче бора башласа да… Куышында анасы үлеп ятса да, баласы коега төшсә дә… Аның аңы-тәне-теләкләре белән мамонт идарә итә. Кешелек тә шулай. Гомер буена шулай чапкан ул: мамонт аулаган, коллар тоткан, җирләр яулаган… Бүген ул мөлкәт артыннан чаба. Капитал артыннан. Бөтен тарих буена нәрсәләрдер артыннан чабып, нидер куып йөргән кавемнең бу дәрәҗәгә ирешүе дә могҗиза инде.



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65, 222-09-70.

E-mail: vtreklama@mail.ru

АЛИНӘЛЕ ТАУ ИЛЕ

Шәфкать иясе

Бу ФАП ишегенең беркайчан да ябылып торганы юк. Авыл халкы бирегә тәненә генә түгел, җанына да дәва эзләп килә. Өлкәнрәк абый-апалар үткән-сүткәндә хәл белергә булса да кереп чыга. Питрәч районының Татар Тау Иле авылы фельдшеры Алинә Мөхәмәтдинова кыска гына вакыт эчендә әнә шулай халыкның мәхәббәтен яулап өлгергән. Фельдшерларының яшь булуы да куркытмый авыл халкын. Ник дигәндә, ике ел эчендә Алинәгә белгеч буларак шактый сыналырга туры килә. Әмма сынатмый ул. Киресенчә, авыл халкының ышанычын яулап, аларның иң якын кешесенә әверелә.

Кечкенәдән курчакларга укол ясап уйнаган Алинә киләчәктә яңа туган балалар белән эшләргә хыяллана. 2015 елда Казан медицина көллиятен тәмамлагач, Казан шәһәренең 13 нче номерлы хатын-кызлар консультациясендә эшли башлый. Тау Иле авылыннан көн дә Казанга йөреп эшли. Ике ел элек үз авылларына фельдшер итеп эшкә чакыралар. Алинә бик теләп ризалаша. Бүген барлыгы 644 кешегә хезмәт күрсәтә ул. Татар Тау Иленнән тыш, күршедәге Рус Тау Иле, Княжа авылларында яшәүчеләр дә Алинә карамагында.

– Баштарак кыенрак булды, билгеле. Казанда тәҗрибәле табиблар белән бергә эшләдем. Ә монда бөтен җаваплылык минем өстә. Прививка, уколларны да үзеңә ясарга кирәк. Беренче көннәрдә балаларга прививка ясаганда аеруча курыктым, – дип искә ала Алинә фельдшер вазыйфасындагы беренче эш көннәрен.

Яңа эш урынына ияләшү – бер хәл. Нәкъ шул чорда коронавирус аркасында пандемия дә башлана. Яңа гына авыл җиренә кайтып эшли башлаган яшь белгеч өчен икеләтә зур сынау чоры башлана. Зур авылга хезмәт күрсәтеп кенә калмый, коронавирус йоктыручыларны да дәваларга керешә ул. Мәкерле чир котырган чорда өйдән-өйгә йөрү, ковид йоктыручылар белән, теләсәң дә, теләмәсәң дә, якыннан аралашу Алинәнең үзе өчен дә эзсез калмаган. Үзе дә авырып алган.

– Үпкәләремә зыян килде. Аның белән авырганнан соң да бик озак тернәкләндем. Коронавирустан соң кан басымы уйный торганга әйләнде. Элек моның нәрсә икәнен дә белми идем. Ковид чорында эшләвем сынау гына түгел, зур тәҗрибә дә булды, – дип искә ала ул көннәрне Алинә Мөхәмәтдинова.

Өлкәннәр үз баласыдай якын күреп, «кызым» дип эндәшә аңа. Күптән түгел авыл халкы Алинәне «коткаручыбыз» дип йөртә башлаган. Һавадан алып әйтелгән сүз түгел бу, билгеле. Орчык кадәр генә батыр йөрәкле кызның авылда ике кеше гомерен саклап калуына сокланып әйтелгән сүз.

– Ул көннәрне искә төшерсәм, әле дә каз тәннәре йөгерә. Авылыбызда бер ир-ат егылган дип хәбәр иттеләр. Тиз арада килеп җиттем. Карасам, абыйда эпилепсия өянәге башланган. «Ашыгыч ярдәм» килеп җиткәнче тиз арада беренче ярдәм күрсәтергә туры килде. Икенчесендә егылып аңын югалткан әби янына чакырдылар. Ул комага ук киткән булып чыкты. Анда да, үз-үземне кулга алып, тиз арада чарасын күрергә туры килде, – ди фельдшер кыз.

Алинә бер урында таптанып тора торганнардан түгел. Әле күптән түгел генә ЭКГ аппаратында эшләргә өйрәнгән, фармацевт һөнәрен дә үзләштергән. Ник дигәндә, якын киләчәктә ФАПта дарулар да сатыла башлар дип көтәләр. Алинә яшерми: арыган, талган чаклары да була. Фельдшерның алы да, ялы да юк бит.

– Бик нык арыган чакларым да була. Эшебез халыкка ярдәм күрсәтү белән генә чикләнми бит. Кәгазь эше дә күп, бар мәгълүматны компьютерга да кертеп барырга кирәк. ФАПны юып, җыештырып тору да минем өстә. Моны авыл халкы да күрә. «Безне ташлап китә күрмә инде», – дип кенә торалар. Китмим, билгеле. Ничек кенә булмасын, эшемне бик яратам, – ди Алинә.

Алинә Мөхәмәтдинованың шәхси архивыннан

Ял көннәрендә, җәйге ялларында да авыл халкы белән гел элемтәдә тора ул. Ярдәм сорап килгән бер кешене дә кире бормый. Төнге уникедә ярдәмгә чакырган чаклар да күп була икән.

– Андый чакта минем белән бергә ирем Самат та ярдәмгә ашыга. Аллаһка шөкер, гаиләм зур терәк миңа. Кызларыбыз Айзилә белән Айсылу үсеп килә. Буш вакытымны алар белән уздырырга тырышам, – ди Алинә Мөхәмәтдинова. – Авылга кайтып эшли башлавыма бер көн дә үкенгәнем юк. Кешеләргә ярдәм итә алуым белән бәхетле мин. Авыл халкыннан «рәхмәт» сүзләре генә ишетеп торгач, күңелгә рәхәт булып китә, бөтен мәшәкатьләр онытыла. «Синең кулларың җиңел, уколны авырттырмыйча ясыйсың», – диләр. Мондый сүзләрдән соң тагын да канатланып эшли башлыйсың.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КИЕМЕҢӘ КАРАП БҮЛӘКЛИЛӘР

Фестиваль

15–23 июль көннәрендә Казанда өченче мәртәбә «Тормыш рәвеше – мәдәни код» этно-fashion фестивале узачак. Шушы чара кысасында «Миллиард.татар» интернет-проекты милли киемнәр парады уздырырга ниятли. Әлеге чара нидән гыйбарәт?

Таңсылу Галимова

Ел саен Республика көнендә башкалада «Милли кием» фестивале узуын беләбез инде. Олысын да, кечесен дә калфак-түбәтәйләр киеп, шәһәр урамына чыгаручы, ялгышмасак, бердәнбер чара ул. Быел менә тагын берсе узачак.

– Милли кием парады «Тормыш рәвеше – мәдәни код» этно-fashion фестивале кысасында узачак. Без аны халык парады дип атадык, чөнки әлеге акциядә теләге булган һәркем катнаша ала, – дип аңлатты Татар мәдәни ресурс үзәге җитәкчесе Алсу Мифтахова.

Инде әйтелгәнчә, милли кием парадында, милләтенә, яшенә, җенесенә карамыйча, һәркем катнаша ала. Хәтта Татарстанда яшәү дә мәҗбүри түгел. Гаиләләре белән катнашучылар аерым игътибарга лаек булачак. Ә катнашу өчен:

– 15 июльдән алып 18 июльгә кадәр Казан Кремленең Кабул итү урыннарына (Присутственные места) яисә Болгарга (фестивальнең кайбер чаралары шунда узачак) милли киемнән килеп, фотога төшәргә, соңыннан шул фотоны социаль челтәрләргә урнаштырырга кирәк;

– #модныйпарадмт хештегын куярга һәм «Миллиард.Татар» аккаунтын билгеләргә онытмагыз.

19 июль кичендә жюри иң яхшы образларны игълан итеп, махсус бүләкләр тапшырачак. Иң яхшы образга «Сәхтиян» брендыннан 20 мең сумлык күн эшләнмә, призлы урыннарга Мәдәният министрлыгыннан махсус милли эшләнмәләр әзерләнгән. Алар шулай ук Казан Кремлендә узачак тантанада да катнашу мөмкинлегенә ия булачак.

– Ләкин шуңа игътибар итәргә кирәк: милли кием дигәч, сәхнәләрдән күреп ияләнгән костюм күз алдына килмәсен. Милли эшләнмәләрне заманча образга яраклаштырырга була. Акция нәкъ менә шуңа басым ясый. Гомумән, без Татарстаныбызда милли дә, заманча да, модалы да киенеп йөрүчеләрнең күбрәк булуын телибез, – диде бу җәһәттән «Buro Banu» брендына нигез салучы һәм аның баш дизайнеры Элара Шәйхи.

Сәламәтлек

Башка капмасын дисәң...

Быелгы җәй башы көзгә чаклы дип җыеп куйган җылы киемнәрне дә кире чыгартты. Әмма июль барыбер үзенекен итте. Терекөмеш баганалары 33–35 градуска кадәр күтәрелде. Җәйге чиллә хакимлек иткән көннәрне ничек уздырырга? Кемнәргә үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк?

Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина ГАЛИУЛЛИНА шул уңайдан киңәшләрен бирде.

Җәйге чиллә йөрәк авырулы, хроник бөер авырулары булган кешеләргә аеруча сак булырга кирәк. Бронхиаль астма, бронхит кебек сулыш авыруларыннан интеккән кешеләрнең дә эссе көннәрдә хәле авыраерга мөмкин.

Җәйге чилләдә кирәксә-кирәкмәсә урамга чыгудан да тыелып торыгыз. Бигрәк тә кояш аеруча кыздырган сәгатьләрдә (11.00 – 17.00 сәгать аралыгында) сак булырга кирәк. Урамга чыккан очракта да ачык төстәге, киҗе-мамык кебек табигый тукымадан тегелгән өс һәм баш киеменә өстенлек бирегез.

Урамга чыкканда үзегез белән чиста су алырга да онытмагыз. Гомумән, җәйге чилләне җиңелрәк кичерү өчен көн дәвамында 1,5–2 литр чиста су эчәргә киңәш ителә. Аны лимон салып эчсәң, тагын да яхшырак. Җәйге эсседән шикәрсез салкын яшел чәй, компот, морслар да коткарачак. Исерткеч, газлы эчемлекләрдән дә баш тарту хәерле. Алар сусауны басмый. Өстәвенә организмдагы матдәләр алмашын да акрынайта. Эчемлекләргә боз салырга да киңәш ителми. Ул баштагы мәлдә генә рәхәтлек бирә. Аннары кеше үзендә хәлсезлек сизәргә мөмкин. Ник дигәндә, бозлы су эчкәндә ашказаны кисәк кысыла. Бу исә нерв системасы эшчәнлеге бозылуга китерә.

Эссе көнне кәһвә эчәргә ярамый дигән фикер яши. Әгәр кеше үзен яхшы хис итә икән, моның бер зыяны да юк дип саныйм. Бары тик бер стакан кәһвә эчкәч, бер стакан чиста су эчеп куярга гына онытмаска кирәк.

Чилләдә яшелчә, парда пешкән балык, тавык кебек җиңел ризыклар белән тукланырга тырышыгыз. Майлы, кыздырылган, баллы ризыкларны чикләү хәерле. Җәйге эссе көннәрдә авыр физик хезмәт, күнегүләр белән организмга өстәмә авырлык китерергә дә ярамый.

Эсседә кондиционер да ярдәмгә килә. Ләкин ул бер яктан хәлне җиңеләйтсә, икенче яктан икеләтә зыян да салырга мөмкин. Шуңа күрә кондиционерны 23 градустан да түбәнрәк температурага куярга ярамый. Юкса салкын тиюе бар.

Бала организмы эссегә күпкә сизгеррәк була. Шуңа күрә алар арасында эссе кагу очраклары да ешрак күзәтелә. Эссе көнне бала үзен начар хис итә башласа, аның иң элек киемнәрен салдырырга, урынга яткырып, салкын суга манылган сөлге белән тәнен уарга кирәк. Һәр 5–10 минут саен су эчертеп торырга да онытмагыз.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 297

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+